**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТӨРНӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

«01» апрель 2026 ел № 21

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 34 номерлы карары белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 апрелендәге 36 номерлы карары белән (2021 елның 28 маендагы 20 номерлы карары белән кертелгән үзгәреш һәм өстәмәләр белән) расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмә үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru/ һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге Советы рәисе С.В. Белов